СОВЕТ ИСКЕ-КАЗАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Куркачи, ул. Клубная, 4

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ-КАЗАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
4227230, Татарстан Республикасы, Биектау
районы, Коркачык авылы, Клуб ур., 4

Тел./факс: +7(84365) 70-700, e-mail:Ikaz.Vsg@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ
24 августа 2020 г.

КАРАР
№ 193

## Биектау муниципаль районының Иске-Казан авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Иске Казан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлегенең норматив хокукый актларын хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә, Иске-Казан авыл җирлеге Советы,

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Советының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалтуын танырга:

2010 елның 18 октябрендәге 4 нче номерлы «Физик затларның мөлкәтенә салым турында»;

2010 елның 30 декабрендәге 22.2 номерлы «Иске-Казан авыл җирлегендә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы Нигезләмәне раслау турында»;

2013 елның 14 февралендәге 92 нче номерлы «Иске-Казан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмеш лампалар җыюны оештыру турында»;

2013 елның 28 маендагы 96 нчы «Иске Казан авыл җирлеге территориясендә тышкы төзекләндерү, тиешенчә карап тоту, җыештыруны оештыру, чисталык һәм тәртипне тәэмин итүне оештыру кагыйдәләре»;

2014 елның 18 февралендәге 160 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәне раслау турында»;

2016 елның 10 ноябрендәге 60 нчы номерлы «Иске Казан авыл җирлеге Советының 2015 елның 28 маендагы 182 нче номерлы Иске Казан авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм санитария тәртибен тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында»;

2017 елның 29 сентябрендәге 85 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Иске Казан авыл җирлеге Советының 2015 елның 24 ноябрендәге «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Г.Р.Закирова